**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур.,1А

**СОВЕТ АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Айбаш, ул.Центральная, 1А

Тел./факс: +7(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** — **РЕШЕНИЕ**

**14 июль 2021 ел** — **№ 25**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик, юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр утыртмаларын кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Биектау районы прокуратурасының 27.05.20021 ел, № 02-01-26-2021 таләбе нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализлау һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Уставына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының 26.03.20021 ел, №16 карары (21.04.20021 ел, №23 карары редакциясендә) белән расланган «Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмә» нең 3 бүлегенең 3.6 пунктына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3.6. Эшләрне башкаруга рөхсәт алган очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларны кискән өчен компенсация бәясе күләмендә түләүләр кертергә тиеш.»;

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы — Р.Р. Сафиуллин